КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 13 июль г.Казань № 649

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 20 август 756 нчы карары белән расланган Яшьләр сәясәте, иреклелек (волонтерлык), яшьләргә хәрби-патриотик тәрбия бирү һәм хәрби хезмәткә чакырылыр алдыннан аларны хәрби хезмәт үтүгә әзерләү өлкәсендәге чараларны һәм яшьләр өчен социаль юнәлештәге башка чараларны оештыру, үткәрү һәм аларда катнашу белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яшьләр сәясәте, ирек-лелек (волонтерлык), яшьләргә хәрби-патриотик тәрбия бирү һәм хәрби хезмәткә чакырылыр алдыннан аларны хәрби хезмәт үтүгә әзерләү өлкәсендәге чараларны һәм яшьләр өчен социаль юнәлештәге башка чараларны оештыру, үткәрү һәм аларда катнашу белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 20 август 756 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабине-тының 2022 ел, 15 июнь, 558 нче; 2023 ел, 6 февраль, 107 нче; 2023 ел, 13 май, 589 нчы; 2023 ел, 22 июнь, 736 нчы; 2023 ел, 4 декабрь, 1551 нче; 2024 ел, 10 гыйнвар, 1 нче; 2024 ел, 13 апрель, 254 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Яшьләр сәясәте, ирекл елек (волонтерлык), яшьләргә хәрби-патриотик тәрбия бирү һәм хәрби хезмәткә чакырылыр алдыннан аларны хәрби хезмәт үтүгә әзерләү өлкәсендәге чараларны һәм яшьләр өчен социаль

юнәлештәге башка чараларны оештыру, үткәрү һәм аларда катнашу белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның икенче абзацында татар текстында «тамашалар» сүзеннән соң «, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгының (алга таба – вәкаләтле орган) йомгаклау коллегияләре» сүзләрен өстәргә;

4 пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы (алга таба – вәкаләтле орган)» сүзләрен «вәкаләтле орган» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин